| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2018 № 10

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 5 декаберендә теркәлде, № 5034

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2018 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2017 елның 25 сентябрендәге 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2018 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2017 елның 25 сентябрендәге 5 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 2 июлендәге 8 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «1291» саннарын «1284» саннарына алмаштырырга;

1 нче кушымтада:

«Татарстан Республикасы җәмгысе» юлында «21265», «1055», «473» тиешенчә «21230», «1054», «472» саннарына алмаштырырга;

217 пунктны көчен югалткан дип танырга;

2 нче кушымтада:

«Татарстан Республикасы җәмгысе» юлында «66577», «5416», «818» саннарын тиешенчә «66343», «5358», «812» саннарына алмаштырырга;

87, 202 пунктларны көчен югалткан дип танырга;

3 нче кушымтада:

«Татарстан Республикасы җәмгысе» юлында «86059», «9,9», «1595», «173», «450», «33», «6», «89», «34» саннарын тиешенчә «85291», «10,0», «1582», «170»,»441», «27», «5», «88», «33» саннарына алмаштырырга;

119, 212, 213, 249 пунктларны көчен югалткан дип танырга.

2. «Яшел Үзән шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ, «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ, «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ, «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ, «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ, «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ директорларына әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән башлап эш көннәрендә исәпләнүче 5 көнлек срокта әлеге карар кабул итүгә бәйле рәвештә 2018 елга инвалидларны эшкә урнаштыру өчен үзләренә билгеләнгән квота саны һәм (яки) инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервка куела торган эш урыннары саны үзгәрә торган эш бирүчеләргә язмача рәвештә хәбәр итәргә.

3. Әлеге карар үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары Таҗетдинова Клара Алексеевнага йөкләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова